ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
Сарман авыл жирлеге
423350 Сарман авылы, Ленин ур., 28
тел.: 2-43-67, 2-45-38

Сармановское сельское поселение
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 28
тел.: 2-43-67, 2-45-38

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабрь 2025 ел **№ 10**

**2020 елның 26 мартындагы 2 номерлы “Җир салымы турында” карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законын 14нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман авыл җирлеге Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» 2020 елның 23 мартындагы 3 номерлы карарына (Советның 05.11.2020 ел, № 11, 28.02.2023 ел, № 2, 02.11.2023 ел, № 21, 07.02.2025 ел, № 1, 24.10.2025 ел № 5 , 25.11.2025 ел №7 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2.2 пунктчасы өстәргә:

   4.2.2. күпфатирлы йортлар астында урнашкан җир кишәрлекләре өчен торак милекчеләре ширкәтләренә;

2. Сарман авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында «2020 елның 26 мартындагы 2 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында» 25.11.2025 ел, № 7 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернетны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.М.Хөснуллин